МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.05.2018 Казан шәһәре № под-778/18

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы ведомствосындагы һөнәри белем бирү оешмаларының методик хезмәтләре җитәкчеләре өчен «Һөнәри белем бирү оешмаларының иң яхшы методик хезмәте җитәкчесе» турында грант

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» гы 2018 елның 12 апрелендәге 238 номерлы Карарын үтәү максатында, шулай ук Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын һәм иҗади активлыгын үстерүне стимуллаштыру максатларында б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомствосындагы һөнәри белем бирү оешмаларының методик хезмәтләре җитәкчеләре өчен «Һөнәри белем бирү оешмасының иң яхшы методик хезмәте җитәкчесе» грантын гамәлгә куярга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомствосындагы һөнәри белем бирү оешмаларының методик хезмәтләре җитәкчеләре өчен «Һөнәри белем бирү оешмасының иң яхшы методик хезмәте җитәкчесе» грантын алуга 2018 елның 6 июненнән 22 июненә кадәр конкурс (алга таба - Конкурс) оештырырга һәм үткәрергә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомствосындагы һөнәри белем бирү оешмаларының методик хезмәтләре җитәкчеләре өчен» «Һөнәри

белем бирү оешмасының иң яхшы методик хезмәте җитәкчесе» гранты турында Положениене расларга.

4. «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенщ (Л. Н. Нугумановага) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының җаваплы вәкиле сыйфатында конкурска оештыру - методик ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә.

5. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (Г. К. Мөхәммәдкәримовага) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомствосындагы һөнәри белем бирү оешмаларының методик хезмәтләре җитәкчеләре өчен «Һөнәри белем бирү оешмасының иң яхшы методик хезмәте җитәкчесе» грантларын түләү эшен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган тәртиптә оештырырга.

6.Урта һөнәри белем бирүне үстерү бүлегенә (Л. А. Митрофановага),боерык чыгарылган көннән соң, эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта, аны Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

7.Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8.Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А. И. Поминовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы

Премьер-министры урынбасары – министр Р.Т.Бурганов

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
03.05. 2018 ел № под-778/18
боерыгы белән

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомствосындагы һөнәри белем бирү оешмаларының методик хезмәтләре җитәкчеләре өчен «Һөнәри белем бирү оешмасының иң яхшы методик хезмәте җитәкчесе» гранты турында
Положение

1. Гомуми положениеләр

1.1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомствосындагы һөнәри белем бирү оешмаларының методик хезмәтләре җитәкчеләре өчен «һөнәри белем бирү оешмасының иң яхшы методик хезмәте җитәкчесе» гранты (алга таба - Грант) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә гамәлгә куела.

1.2.Чарада катнашучылар булып торалар:

грант бирүче - Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба - министрлык);

грант алырга теләүче - министрлык карамагындагы һөнәри белем бирү оешмасының методик хезмәте җитәкчесе, ул - әлеге вазыйфада 1 елдан да ким булмаган эш тәҗрибәсе булган, штат расписаниесе нигезендә директор урынбасары (фәнни-методик эш, инновацион эшчәнлек буенча һ. б.), методист, методик кабинет мөдире (вазыйфаи бурычлары һөнәри белем бирү оешмасының методик хезмәте белән җитәкчелек итә торган);

грант алучы- әлеге Положениедә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган, конкурс сайлап алуын узган һәм рейтингта 1-20 нче урыннарны алган министрлык карамагындагы һөнәри белем бирү оешмасының методик хезмәте җитәкчесе;

грант алучыларга 12 ай дәвамында түләнә торган 8 046 (сигез мең кырык алты) сум күләмендә айлык өстәмә акча Грант булып тора.

Грант алучы ел саен грантта катнашырга хокуклы.

1.3. Грант алуга Конкурс (алга таба - Конкурс) Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларында методик эшчәнлекне үстерүне стимуллаштыру максатларында һәм «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында Мәгариф һәм фәнне үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында Министрлык тарафыннан «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе белән берлектә уздырыла.

1.4.Конкурсның бурычлары булып тора:

Татарстан Республикасы урта һөнәри белем бирү системасында методик эшне оештыруның иң яхшы модельләрен ачыклау;

методик хезмәтнең нәтиҗәле җитәкчеләренә ярдәм итү;

Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының инновацион эшчәнлеге тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату.

1.5.Грант бирүче гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганчы, 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - министрлык сайты) мәгълүмат урнаштыру юлы белән конкурс үткәрү турында игълан итә.

1.6.Конкурс ике этапта үткәрелә:

1.6.1. конкурсның беренче республика (читтән торып катнашу) этабы-2018 елның 6-7 июнь көннәрендә;

1.6.2. конкурсның икенче республика (турыдан - туры) этабы-2018 елның 18-20 июнь көннәрендә.

## 2.Конкурсны оештыру

2.1.Конкурсны оештыру-методик тәэмин итүне һәм уздыруны составында комиссия рәисе, җаваплы сәркатиб һәм әгъзалары булган Республика конкурс комиссиясе гамәлгә ашыра.

2.1.1 Республика конкурс комиссиясенең персональ составы Министрлык боерыгы белән раслана.

Республика конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның составының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы санала.

2.1.2. Республика конкурс комиссиясе:

массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка ысуллар аша конкурсны үткәрү шартлары, тәртибе һәм вакытлары турында игълан итә;

катнашучылардан гаризалар кабул итә;

эксперт комиссиясе эшен туплый һәм оештыра;

Конкурсны оештыра;

Конкурска йомгак ясый;

Конкурс нәтиҗәләрен бастыруны оештыра;

грантны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча хисап кабул итә.

2.1.3. Конкурсның беренче Республика (читтән торып катнашу) этабын үткәрү нәтиҗәләре белән килешмәгән очракларда, грант алырга теләүче республика конкурс комиссиясенә апелляция бирергә хокуклы. Апелляция master.tatarstan@mail.ru электрон почтасы аша Министрлыкның һәм «ТР мәгарифне үстерү институты» ӨҺББ ДАМУнең рәсми сайтларында грант алырга теләүчеләрне конкурсның икенче (турыдан-туры) республика этабына чыгару турында Республика конкурс комиссиясе карарлары басылып чыккан көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнгән ике көнлек срокта Республика конкурс комиссиясе рәисе исеменә ирекле рәвештә тапшырыла.

2.1.4. Республика конкурс комиссиясе, апелляция бирү вакыты тәмамланганнан соң, бер эш көне эчендә апелляцияне карый. Республика конкурс комиссиясе конкурс материалларын бәяләгәндә, эксперт комиссиясе тарафыннан хокук бозулар булу-булмавын билгели, шулай ук ул бәяләү балларын аргументацияләү өчен, экспертларны чакыру хокукына да ия. Апелляцияне карау нәтиҗәләре буенча Республика конкурс комиссиясе түбәндәге карарларның берсен чыгара:

апелляцияне кире кагу һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне саклап калу турында;

апелляцияләр канәгатьләнү, грант алырга теләүчене республика этабындагы икенче (турыдан-туры)этабына чыгару һәм аны икенче республика (турыдан-туры) этабындагы катнашучылар исемлегенә кертү турында.

Апелляция буенча Республика конкурс комиссиясе карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, республика конкурс комиссиясе рәисе хәлиткеч тавыш бирергә хокуклы.

2.2. Конкурсның беренче (читтән торып катнашу) республика этабындагы конкурс материалларын һәм икенче (турыдан-туры) республика этабындагы конкурс биремен бәяләү өчен Эксперт комиссиясе төзелә.

2.2.1. Эксперт комиссиясенең персональ составы Министрлык боерыгы белән раслана.

2.2.2. Экспертлар сыйфатында министрлык, Татарстан Республикасы профсоюз оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары, Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмалары директорлары Советы, Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмалары һәм башка оешмалар вәкилләре җәлеп ителергә мөмкин.

2.2.3. Экспертиза вакытында тәэмин ителә:

грант алырга теләүченең эшчәнлеген бәяләү критерийлары нигезендә бәяләүнең объективлыгы;

конфиденциальлек (шул исәптән конкрет катнашучыны бәяләүдә катнашмаган эксперт комиссиясе әгъзаларына карата да).

2.2.4. Эксперт комиссиясе әлеге Положение нигезендә билгеләнгән критерийлар нигезендә грант алырга теләүчеләрнең конкурс материалларын бәяли.

Баллар эксперт битләренә кертелә, экспертлар имзасы белән таныклана һәм Эксперт комиссиясе рәисенә тапшырыла.

2.2.5. Эксперт битләре нигезендә грант алырга теләүчеләрнең рейтингы төзелә. Эксперт комиссиясе рәисе һәм әгъзалары кул куйган Рейтинг Республика конкурс комиссиясенә тапшырыла.

2.3. Конкурс йомгаклары буенча республика конкурс комиссиясе рейтинг нигезендә грант алучылар исемлеген төзи.

## 3. Конкурсны үткәрү

3.1. Конкурста катнашу өчен гариза түбәндәге адрес буенча master.tatarstan@mail.ru электрон почта аша Грант алырга теләүче тарафыннан 2018 елның 5 июненнән дә соңга калмыйча җибәрелә:

3.1.1. «ТР мәгарифне үстерү институты » ӨҺББ ДАМУ грант алырга теләүчеләр тарафыннан җибәрелгән гаризалар буенча буенча мәгълүмат җыелмасын тәэмин итә.

3.1.2. Гариза 2018 елның 5 июненнән дә соң тапшырылган очракта, грант алырга теләүче Конкурста катнашу хокукыннан мәхрүм ителә.

3.2. Конкурсның беренче республика (читтән торып катнашу) этабы билгеләнгән график нигезендә 2018 елның 6-7 июнендә конкурс (мәгълүмати) материалларына эксперт комиссиясе тарафыннан уздырылган экспертиза формасында үткәрелә.

3.1. Конкурсның читтән торып катнашу этабын үткәрү графигы һәм урыны Республика конкурс комиссиясе тарафыннан раслана.

3.1.2. Конкурсның читтән торып үткәрелә торган этабы турында катнашучыларга хәбәр итү «Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты» ӨҺББ ДАМУнең рәсми сайтында, 2018 елның 6 июненнән дә соңга калмыйча, мәгълүмат бастырып чыгару юлы белән гамәлгә ашырыла.

3.3. Грант алырга теләүче, Конкурсның беренче республика (читтән торып катнашу) этабында катнашу өчен, билгеләнгән график нигезендә Эксперт комиссиясе утырышына тәкъдим итә:

һөнәри белем бирү оешмасының оештыру моделе (системасы) буенча мәгълүмати материаллар, үз эченә методик эшне оештыру-хокукый тәэмин итүне, методик хезмәтнең оештыру структурасын, методик эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләренең максатларын һәм бурычларын, методик эшнең оештыру һәм дидактик рәвешләрен һ. б. кирә торган материалларны ( күләме 20 биттән артмаска тиеш (кушымталарны санамыйча гына);

эшчәнлек юнәлеше буенча инновацион педагогик проект паспортын (алга таба-Проект). Бирелә торган материал күләме 5 биттән артмаска тиеш.

3.3.1. Материаллар электрон һәм басма вариантта *doc (А-4) күләме шрифта 14 Times New Roman, интервал 1,15.форматында бирелә/

3.3.2. Билгеләнгән таләпләрне бозып әзерләнгән һәм графикта күрсәтелгән сроктан соңрак кергән материаллар кабул ителми.

Һөнәри белем бирү оешмасы грант алырга теләүчеләрнең тәкъдим ителгән материалларының сыйфаты һәм дөреслеге өчен җавап бирә.

3.3.3. Баллар һәр критерий буенча исәпләнә һәм кушыла. Конкурс нигезендә сайлап алуның һәр критерие буенча грант алырга теләүчеләргә Эксперт комиссиясе әгъзаларын тарафыннан куелган баллар суммасы буенча грант алырга теләүчеләрнең рейтингы төзелә. Эксперт комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм, 2018 елның 7 июненнән дә соңга калмыйча, Республика конкурс комиссиясенә кертелә.

3.3.4. Конкурсның турыдан-туры этабында катнашучылар дип рейтингта 1-30 урыннарга чыккан грант алырга теләүчеләр таныла.

3.4. Конкурсның икенче республика (турыдан - туры) этабы (алга таба- конкурсның турыдан-туры этабы) 2018 елның 18-20 июнендә проектны яклау форматында үткәрелә.

3.4.1. Проект эксперт комиссиясенә кәгазьдә тәкъдим ителергә һәм мультимедиа презентациясе белән үрелеп барырга тиеш. Яклау регламенты-7 минуттан да артык түгел.

3.4.2. Конкурсның турыдан-туры этабын үткәрү графигы һәм урыны Республика конкурс комиссиясе тарафыннан раслана.

3.4.3. Конкурсның турыдан-туры этабында катнашучыларга график һәм үткәрү урыны турында хәбәр итү «Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты» ӨҺББ ДАМУның рәсми сайтында, 2018 елның 8 июненнән дә соңга калмыйча, мәгълүмат бастырып чыгару юлы белән гамәлгә ашырыла.

3.4.4. Конкурсның турыдан-туры этабы нәтиҗәләре буенча Эксперт комиссиясе карары төзелә, ул беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм Республика конкурс комиссиясенә 2018 елның 21 июненнән дә соңга калмыйча кертелә.

3.5. Грант алырга телләүчеләрнең рейтингы нигезендә грант алучылар исемлеге төзелә һәм Министрлык боерыгы белән раслана.

3.6. Грантны гамәлгә ашыру кысаларында грант алучы проект чараларын үтәү буенча эшне оештырырга тиеш. Башкарылган эшләр турында хисап, барлык нәтиҗәләрне тасвирлап һәм анализлап, Грантны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча Республика комиссиясе утырышында тәкъдим ителергә тиеш.

3.6.1. Грантны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча хисап бирү формасы һәм Республика комиссиясе утырышларын уздыру графигы Грант алучыларга, конкурс нәтиҗәләрен игълан итү датасыннан да соңга калмыйча, өстәмә рәвештә хәбәр ителә.

## 4. Грант алырга теләүчеләрнең Конкурс материалларын һәм конкурс биремнәрен бәяләү

4.1. Конкурсның читтән торып катнашу этабы материаллары түбәндәге күрсәткечләр нигезендә баллы система буенча конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләнә:

| Күрсәткеч атамасы | Материаллар төре | Бәяләү критерийлары | Балларда бәя |
|---|---|---|---|
| Һөнәри белем бирү оешмасының методик эш системасының нәтиҗәлелеге (0-80 балл) | һөнәри оешманың методик эш буенча оештыру моделе (системасы) буенча мәгълүмати материаллары | методик эшне оештыруны регламентлаучы локаль норматив актлар һәм программа документлары пакетын формалаштыру. | 0-5 |
| | | һөнәри белем бирү оешмасының методик хезмәте | 0-10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | структурасының нигезле булуы | |
| | | һөнәри белем бирү программаларын эшләү һәм актуальләштерү процессларының системалылыгы. | 0-10 |
| | | педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү һәм тарату механизмнарын эшләү. | 0-10 |
| | | педагогларның һөнәри компетентлыгын арттыру комплекслылыгы. | 0-10 |
| | | фәнни һәм инновацион эшчәнлекне оештыру нәтиҗәлелеге. | 0-15 |
| | | методик эшчәнлекне планлаштыру һәм оештыру нәтиҗәлелеге. | 0-10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | эшчәнлек механизмнарын эшләү. | 0-10 |
| | | методик эшчәнлек нәтиҗәләрен мотивацияләү һәм бәяләү механизмнарын эшләү. | 0-10 |
| Планлаштырылган инновацион эшчәнлекне бәяләү (0-20 балл). | инновацион педагогик проект паспорты. | проектның актуальлеге (практик һәм инновацион әһәмияте, һөнәри белем бирүнең сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгәнлеге). | 0-6 |
| | | педагогик проект максатларының һәм бурычларының төгәллеге, ирешүчәнлеге. | 0-6 |
| | | проект этапларын сайлау дөреслеге. | 0-2 |
| | | проектның нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре һәм методларының эшкәртелүе. | 0-6 |

4.1.1. Баллар һәр критерий буенча исәпләнә һәм кушыла. Конкурсның читтән торып катнашу этабында катнашучы ала торган максималь баллар саны-100. Грант алырга теләүче рейтингта балларның суммар күрсәткече кимү тәртибендә урнаша.

4.2. Конкурс материалларының эчтәлеге түбәндәге критерийлар нигезендә балл системасы буенча эксперт комиссиясе тарафыннан бәяләнә:

| Күрсәткеч атамасы | Бәяләү критерийлары | Балларда бәя |
|---|---|---|
| Актуальлек (0-30 балл) | Урта һөнәри белем бирүне үстерүнең заманча тенденцияләренә туры килү. | 0-10 |
| | һөнәри белем бирү оешмасының үсешенә юнәлдерелгән булуы. | 0-10 |
| | проектның трансляцион җәлеп итүчәнлеге, ягъни аның нәтиҗәләрен коллегаларның эшчәнлегенә мәгариф оешмасы, район, шәһәр, республика һәм башка югары уку йортлары дәрәҗәсендә кертү мөмкинлеген тәэмин итү. | 0-10 |
| Проект бүлекләренең эшкәртелүе (0-50 балл). | проблемалы вазгыятьне һәм тиешле педагогик проблеманы (проблемаларны) хәл итүгә (аларны) юнәлдерелгән корректлылык. | 0-12 |
| | куюның төгәллеге, педагогик проект максатларының һәм бурычларының ирешүчәнлеге, проектта бүлеп бирелгән проблемалардан максат һәм бурычларның дөреслеге. | 0-13 |
| | проект этапларын сайлауның дөреслеге, гамәлләр тәртибен үтәү, чаралар җыелмасын чикләүнең дөреслеге. | 0-12 |
| | проектның нәтиҗәлелеген бәяләү | 0-13 |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәткечләре һәм методларының адекватлыгы,проектның нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләр җитәрлек булуы. | |
| Презентациялелек (0-20 балл). | грант алырга теләүченең шәхси һәм профессиональ сыйфатларын чагылдыра торган презентациянең логик эзлеклелеге һәм бөтенлеге. | 0-10 |
| | коммуникацион эффектлар (игътибар җәлеп итү алымнары, сөйләмнең дөреслеге, сәнгать чагылышы чараларын куллану һ. б.) | 0-10 |

4.2.1. Баллар һәр критерий буенча исәпләнә һәм кушыла. Конкурсның читтән торып катнашу этабында катнашучы ала торган максималь баллар саны-100. Грант алырга теләүче рейтингта балларның суммар күрсәткече кимү тәртибендә урнаша.

5.Җиңүчеләрне игълан итү

5.1. 2018 елның 21 июнендә конкурсның турыдан-туры этабы нәтиҗәләре буенча Республика конкурс комиссиясе грант алучылар исемлеген формалаштыра.

5.2. «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесеКонкурсның турыдан-туры этабында катнашучыларга катнашу турында сертификатлар тапшырыла.

5.4. Грант алучының һөнәри белем бирү оешмасы белән хезмәт килешүе өзелгән очракта, баланы өч яшькә җиткәнче карау өчен ялга чыкканда, грант бирү турындагы карар гамәлдән чыгарыла һәм түләүләр туктатыла.

5.5. Грант алучы эшләгән һөнәри белем бирү оешмасы 5 эш көне дәвамында министрлыкка грант алучы белән хезмәт килешүенең өзелүе, яки Грант алучының, баланы өч яшькә җиткәнче карау өчен ялга чыгуы турында хәбәр итәргә тиеш.

6.Грантны финанслау

Дәүләт грантын бирү максатларында субсидия бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Кушымта 1
Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгы ведомствосындагы
һөнәри белем бирү оешмаларының
методик хезмәтләре җитәкчеләре
өчен һөнәри белем бирү оешмасының
“Иң яхшы методик хезмәте җитәкчесе”
гранты турындагы положениегә

***Һөнәри белем бирү оешмасының “Иң яхшы методик хезмәте җитәкчесе” грантын алуга конкурста катнашу өчен гариза***

Белем бирү оешмасы (белем бирү оешмасының рәсми исемен күрсәтергә)________________________________________________

Мәгариф оешмасы җитәкчесе (Ф. И. О. тулысынча)________________________________________________

(телефон)________________________________________________

(электрон адрес. почта)________________________________________

Белем бирү оешмасының юридик адресы (почта индексын күрсәтеп).________________________________________________

Телефон_______________, факс________________________

Конкурста катнашу өчен җибәрәбез:

| № п/п | Катнашучының исем-фамилиясе | Эш стажы | Вазифа |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |

Дата (саны; ай) 2018 ел.

*[Култамга] [вазыйфа]* мәгариф оешмасы мөһере

Кушымта 2
Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгы ведомствосындагы
һөнәри белем бирү оешмаларының
методик хезмәтләре җитәкчеләре
өчен һөнәри белем бирү оешмасының
“Иң яхшы методик хезмәте җитәкчесе”
гранты турындагы положениегә

***Һөнәри белем бирү оешмасының “Иң яхшы методик хезмәте җитәкчесе” грантын алуга конкурста катнашучы анкетасы***

Конкурсантның исем-фамилиясе______________________________________________

Педагогик эшчәнлек урыны___________________________________________________

Белем (мәгариф оешмасын, факультетын күрсәтеп,).____________________________________________________________

Белгечлеге буенча диплом____________________________________________________

Мактаулы исемнәр (бүләкләр).________________________________________________

Педагогик стажы.__________ Әлеге вазыйфасы буенча стажы._________________

Категория а) __________бар б) ________________________________-дәгъвалыйм

Йорт адресы.________________________ тел./сот.__________________________

Педагогик эшчәнлек алып барыла торган һөнәр.

Мәгълүмати (компьютер) технологияләренә ия булу: компьютерны белмим, педагогик эшчәнлектә кулланам (басым ясарга кирәк).

Тутыру датасы «_____»__________________ Шәхси имза__________

Кушымта 3
Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгы ведомствосындагы
һөнәри белем бирү оешмаларының
методик хезмәтләре җитәкчеләре
өчен һөнәри белем бирү оешмасының
“Иң яхшы методик хезмәте җитәкчесе”
гранты турындагы положениегә

## ПРОЕКТ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Проектның исеме | <Проектның исемен күрсәтергә> |
| Проект җитәкчесе | <Проект җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Ф. И. күрсәтергә> |
| Проектта катнашучылар | <Проектка җәлеп ителгән бүлекчәләрнең һәм катнашучыларның исемнәрен күрсәтергә>. |
| Проектның инициациясенә нигез булып торган стратегик максат | <Конкрет стратегик максатны күрсәтергә, проектның әлеге максатка туры килүен нигезләргә>. |
| Проект кирәклеген нигезләү | < Югарырада күрсәтелгән стратегик максатларга ирешү ирешү өчен проектның кирәклеген нигезләргә >. |
| Проектның максаты (максатлары). | <Проектның максатын (максатын) күрсәтергә>. |
| Проектның бурычлары | <Проектның бурычларын күрсәтергә>. |
| Проектның нәтиҗәсе (нәтиҗәләре). | <Проектны гамәлгә ашыру юлы белән ирешәчәк проектның планлаштырылган нәтиҗәсен (нәтиҗәләрен) күрсәтергә>. |
| Проектның уңыш критерийлары | <Проектны уңышлы тәмамлау критерийларын (критерийларын) күрсәтергә>. |
| Проектны тормышка ашыру вакыты | <Этапларны (кирәк булганда) билгеләп, |

| | |
|---|---|
| | проектны гамәлгә ашыруның башлану һәм тәмамлану датасын күрсәтергә |
| Проектны гамәлгә ашыру куркынычы | < Проектны тормышка ашыру чикли торган (ресурс чикләүләр, чикләүләр белән бәйле законнар һ.б.), шулай ук проектның куркынычлыгын идентификацияләү факторларын күрсәтергә >. |
| Куркынычларны бетерү буенча тәкъдимнәр. | <Рискларны киметүгә юнәлдерелгән чараларны күрсәтергә>. |
| Башка проектлар белән үзара бәйләнеш | <Үзара бәйле проектларны күрсәтергә>. |